РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1503

2022 елга Әлмәт муниципаль районы
гомуми белем бирү учреждениеләренең
норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында»2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 11 декабрендәге 3100 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 1644 номерлы карары 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) әлеге карарның 1 пункты белән расланган гомуми белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 305-2000

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«28» октябрь 2021 ел №1503
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләре һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы Интернат | шәһәр җирлеге | 97 391 |
| | авыл җирлеге | 98 753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 143 889 |
| | авыл җирлеге | 148 363 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптева